| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**11.01.2021** Кукмара ш. **№ 08**

2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру буенча муниципаль Программаны раслау турында

1. «2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру буенча муниципаль Программаны раслау турында муниципаль программаны расларга (кушып бирелә)

2. Кукмара муниципаль районының муниципаль учреждениеләренә Кукмара муниципаль районы бюджетын формалаштыру һәм аның үтәлешен оештыруда Программа нигезләмәләренә таянып эш итәргә.

3. Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда, Программа чараларын тормышка ашыруга, мөмкинлекләрне исәпкә алып, һәм күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә акча күздә тотарга.

4. «2015 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру буенча муниципаль программаны раслау турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 23 декабрендәге 511 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М.Әхмәтшинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 11.01.2021 №08 карарына кушымта

2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру

программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру буенча муниципаль Программа (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия милләтенең бердәмлеген ныгыту һәм Россия халыкларының этномәдәни үсеше (2014 – 2020 еллар)» федераль максатчан программасы;<br>«Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы;<br><br>«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br><br>2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы<br>2014 – 2016 еллар чорына татар халкының этник тәңгәллеген саклау концепциясе |
| Программаны төп эшләүчеләр | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләре һәм идарәләре |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максатлары – Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче халык вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклап калу, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (Россия милләте) ныгыту, мигрантларны уңышлы социомәдәни җайлаштыру һәм интеграцияләү.<br><br>Программаның бурычлары: |

| | |
|---|---|
| | - Дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеген камилләштерү;<br><br>- Гражданлык тәңгәллеген ныгытуга ярдәм итү, этникара һәм конфессияара тынычлыкка һәм татулыкка ярдәм итү, мигрантларны социаль-мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү өчен шартлар тудыру;<br><br>- Кукмара муниципаль районында яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру;<br><br>- Халыкның, бигрәк тә авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү;<br><br>- Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ туфракта конфликтларны кисәтү һәм булдырмау. |
| Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре | Кукмара муниципаль районында этникара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяләүче район халкы өлеше;<br><br>башка милләт вәкилләренә карата толерант мөнәсәбәт дәрәҗәсе;<br><br>Россия халыкларының этномәдәни үсешенә һәм тел төрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны;<br><br>Кукмара муниципаль районында конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышын уңай бәяләүче район халкы өлеше;<br><br>үзләренең этномәдәни ихтыяҗларын тормышка ашырудан канәгать булган район халкы өлеше. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2021 – 2023 еллар.<br><br>I этап: 2021 ел<br>II этап: 2022 ел<br>III этап: 2023 ел |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм | Программаны финанслауның гомуми күләме 4524,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: |

<table>
<tr>
<td>чыганаклары:</td>
<td>
<table>
<tr><th>Финанслау чыганагы</th><th>2021 ел</th><th>2022 ел</th><th>2023 ел</th></tr>
<tr><td>Район бюджеты</td><td>1508,0</td><td>1508,0</td><td>1508,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1508,0</td><td>1508,0</td><td>1508,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре</td>
<td>
- милли мәдәни традицияләрне саклауга ярдәм итү;<br>
- туган телләрне саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру;<br>
- милли берләшмәләрне районның социаль-мәдәни һәм сәяси тормышына кушу;<br>
- милләтара һәм конфессияара диалогны үстерү эшчәнлегенә иҗтимагый, дини оешмаларны җәлеп итү;<br>
- халыкны, балаларны һәм яшьләрне толерантлык рухында тәрбияләүгә, барлык милләтләр һәм халыкларның үзара хөрмәтенә юнәлдерелгән чараларга җәлеп итү;<br>
- яшьләр сәясәте һәм патриотик тәрбия өлкәсендә инновацион, проект эшчәнлегенә системалы ярдәм күрсәтү;<br>
- районның тарихи-мәдәни мирас объектларын саклау һәм торгызу, аларны мәдәни-агарту эшчәнлегендә һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшендә куллану буенча система булдыру;<br>
- физкультура-сәламәтләндерү һәм интеллектуаль-иҗади чараларга җәлеп ителгән авыл яшьләре санын арттыру;<br>
- халык, бигрәк тә яшьләр арасында җинаятьчелек, эчкечелек һәм наркомания дәрәҗәсенең киметү;<br>
- милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә тотрыклылыкны саклап калу, милләтара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяләүче гражданнар өлешен арттыру;<br>
- Программа чараларын нәтиҗәле тормышка ашыру;
</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - Кукмара муниципаль районы территориясендә башка мәдәниятләргә карата толерантлык, хөрмәт идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълүмати киңлек булдыру;<br>- яшьләр арасында этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру | Программаны тормышка ашыруны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота. |

## I. Программа хәл итәргә тиешле проблеманың характеристикасы

Хәзерге вакытта Кукмара муниципаль районында тулаем алганда, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең уңай климаты саклана.

Кукмара муниципаль районы территориясендә социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси хәл тотрыклы.

Район халкының социаль-демографик күрсәткечләре: 78,2% – татарлар, 5,5% – руслар, 14,2% – удмуртлар, 1,6% – марилар, 0,5% - башка милләтләр (чуашлар, башкортлар, ненецлар, әрмәннәр, үзбәкләр, греклар һәм башка милләтләр).

Күпмилләтле җәмгыятьне берләштерү һәм милли үзаңны арттыру процессларында милли традицияләрне саклауга, яңадан торгызуга һәм алга таба үстерүгә юнәлдерелгән халык бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләр мөһим роль уйный.

Милли, миграция, яшьләр һәм мәгълүмат сәясәтендә, мәгариф, физик культура һәм спорт системасында, хокук саклау һәм җирле берләшмәләрнең программалы-максатчан метод нигезендә тормышка ашырыла торган комплекслы системалы гамәлләр районда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең кискенләшүен булдырмаска ярдәм итәчәк.

Программа милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең уңай характерын саклап калуга юнәлдерелгән.

Районда милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы тотрыклылык, төрле этник төркемнәр һәм конфессияләр вәкилләренең үзара тыныч аралашуы һәм хезмәттәшлеге белән характерлана.

Яшь буынны районда яшәүче халыкларның мәдәниятенә, теленә, гореф-гадәтләренә, йолаларына хөрмәт рухында тәрбияләү, белем бирү процессында гуманитар юнәлешнең ролен арттыру, милли телләрдә белем һәм тәрбия бирү системасын үстерү өчен хокукый һәм матди шартлар булдыру буенча максатчан

эш алып барыла.

Милли мөнәсәбәтләр үсеше перспективаларын исәпкә алып, район алдында яңа бурычлар тора, аларны хәл итү заманча концептуаль алымнар таләп итә.

Иҗтимагый-сәяси, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы, гомумән алганда, тотрыклы, дустанә, төрле социаль төркемнәр, милләт һәм дин вәкилләренең үзара конструктив бәйләнеше һәм хезмәттәшлеге белән характерлана. Экстремистлык күренешләре күренми. Җирле халык традицион булмаган ислам тарафдарларына тискәре мөнәсәбәттә.

Әлеге программа гражданнарның күп гасырлык үзара хөрмәт һәм тату яшәү традицияләре нигезендә этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

Программа этникара мөнәсәбәтләр өлкәсендә яңа проблемаларны хәл итәргә, Татарстан Республикасының күпмилләтле халкының этномәдәни үсешен саклап калырга һәм яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

## II. Программаның максатлары, бурычлары, сроклары (этаплары) һәм максатларына ирешү һәм бурычларны хәл итү күрсәткечләре (индикаторлары)

Программаның максатлары һәм бурычлары «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте Стратегиясендә билгеләнгән өстенлекле юнәлешләре һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясе турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясе белән, Программаның максатлары һәм бурычлары федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсенә кагылышлы башка норматив хокукый актлар белән бәйле.

Программаның максатлары – Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче халык вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклап калу, мигрантларны уңышлы социомәдәни җайлаштыру һәм интеграцияләү.

Куелган максатларга ирешү түбәндәге бурычларны тормышка ашыруны

күздә тота:

1. Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеген камилләштерү;

2. Гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгытуга ярдәм итү, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны булдыру һәм аларга ярдәм итү, мигрантларны социаль-мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү;

3. Кукмара муниципаль районында яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру;

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2021 – 2023 еллар.

Программаны гамәлгә ашыру 3 этапта башкарыла:

I этап (2021 ел). I этапның максаты – Кукмара муниципаль районында дәүләт милли сәясәте өлкәсендә уңай алга китеш формалаштыру.

II этап (2022 ел). II этапның максаты – I этапта барлыкка килгән уңай тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту.

III этап (2023 ел). III этапның максатыКукмара муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү өлкәсендә тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешү.

## III. Программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 4524,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

| Финанслау чыганагы | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
|---|---|---|---|
| Район бюджеты | 1508,0 | 1508,0 | 1508,0 |
| барлыгы | 1508,0 | 1508,0 | 1508,0 |

Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны эшләүче планлаштыруны, үзара хезмәттәшлек, координацияләү һәм аның үтәлешен гомуми контрольдә тота, ул ел саен Программаның максатчан күрсәткечләрен һәм чараларына чыгымнарны, аны тормышка ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын аныклый, чараларны үтәү өчен җаваплы кешеләрдән Программаны үтәү барышы турында мәгълүмат соратып ала.

Программаны тормышка ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеген үз эченә алган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар программаны эшләүчегә чараларның үтәлеше һәм башкаручыларга бүлеп бирелә торган акча средстволары турында үсеш нәтиҗәсе белән һәм тулаем алганда хисап елы өчен мәгълүмат бирәләр.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

**Эшләр идарәчесе** **Р.З.Минһаҗева**

**2021 – 2023 елларда Кукмара районында**
**этникара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү буенча гамәлләрнең**
**КОМПЛЕКСЛЫ ПЛАНЫ**

| № | Чараның исеме, темасы | Үткәрү вакыты | Җаваплылар | Финанслау күләме (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| **I бүлек Оештыру эшчәнлеге** | | | | | | |
| 1. | Муниципаль район Башлыгы каршындагы дини мөнәсәбәтләр буенча Советның эшен оештыру | Ел дәвамында | Муниципаль район Башкарма комитеты | - | - | - |
| 2. | Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча комиссия утырышлары | Квартал саен | Муниципаль район Башкарма комитеты | - | - | - |
| 3. | Муниципаль район якташлар җәмгыятьләре утырышлары | Ел дәвамында | Район Советы аппараты | - | - | - |
| 4. | Районның террорчылыкка каршы комиссиясе утырышы | Квартал саен | Гарифуллин Р. Р. комиссия секретаре | - | - | - |
| 5. | Хокук саклау органнары вәкилләре белән районда миграция вәзгыяте мәсьәләләре буенча район Башлыгы каршында киңәшмә | Квартал саен | Район Советы аппараты | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Районның иҗтимагый оешмалары утырышлары:<br><br>- Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Кукмара бүлекчәсе<br><br>ТР Кукмара муниципаль районы удмуртларның милли-мәдәни автономиясе<br><br>- ТР керәшеннәр иҗтимагый оешмасының Кукмара бүлеге<br><br>- «ТР рус милли-мәдәни берләшмәсе» Кукмара Региональ иҗтимагый оешмасының Кукмара бүлекчәсе<br><br>- «Мариларның милли-мәдәни автономиясе» Кукмара Региональ иҗтимагый оешмасының Кукмара бүлекчәсе<br><br>- Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының Кукмара бүлекчәсе | Ел дәвамында<br><br>квартал саен<br><br>квартал саен<br><br>квартал саен<br><br>квартал саен<br><br>Квартал саен | Җиһаншина З. Н.<br><br>Семенов В. Г.<br><br>Афанасьев А. Н.<br><br>Бурцева С. В.<br><br>Искаков Л. А.<br><br>Җиһаншина З. Н. | -<br>-<br>-<br>-<br>-<br>- | -<br>-<br>-<br>-<br>-<br>- | -<br>-<br>-<br>-<br>-<br>- |
| 7. | Районда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мониторингын оештыру | Ел дәвамында | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), район Башлыгы каршындагы дини оешмалар белән | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | хезмәттәшлек итү Советы | | | |
| **II бүлек Татарстан халыкларының милли мәдәниятләрен саклау һәм үстерү** | | | | | | |
| 8. | Предприятиеләр, оешмалар, мәктәпләр һәм балалар бакчалары арасында район халык иҗаты фестивале | Ел дәвамында | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **20,0** | **20,0** | **20,0** |
| 9. | Авыл җирлекләре үзешчәннәренең театральләштерелгән тамаша смотр-конкурсы | Ел дәвамында | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **50,0** | **50,0** | **50,0** |
| 10. | Балалар театр коллективларының район смотры | Ел дәвамында | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **10,0**<br><br>**10,0** | **10,0**<br><br>**10,0** | **10,0**<br><br>**10,0** |
| 11. | «Дары Волхвов» Раштуа рухи һәм халык музыкасы фестивален уздыру | Гыйнвар | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>АНО «ШийЭнер»<br><br>Кукмара балалар сәнгать мәктәбе<br><br>Кукмара муниципаль районы «Халыклар дуслыгы йорты» МБУ | **20,0** | **20,0** | **20,0** |
| 12. | «Кукмара кышы» татар җыры район фестиваль конкурсы | Гыйнвар | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **30,0** | **30,0** | **30,0** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Районда яшәүче халыкларга багышланган күргәзмә, йорт-каралтылар (подворья) оештыру | Ел дәвамында (тематик гомумшәһәр чаралары үткәрү вакытында) | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ, районның туган якны өйрәнү музее | **50,0** | **50,0** | **50,0** |
| 14. | «Созвездие-Йолдызлык» эстрада сәнгатенең ачык республика телевизион яшьләр фестивалендә катнашу | Февраль-Апрель | «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ<br><br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МУ | **100,0**<br><br>**10,0** | **100,0**<br><br>**10,0** | **100,0**<br><br>**10,0** |
| 15. | «Май чабу» халык бәйрәмен, традицион халык күңел ачуларын оештыру һәм үткәрү | Март | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>«ТР рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының Кукмара бүлекчәсе | **5,0**<br><br>**-** | **5,0**<br><br>**-** | **5,0**<br><br>**-** |
| 16. | Төрки халыкларның язгы «Нәүрүз» – «Кыш озату» бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Март | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **10,0**<br><br>**5,0** | **10,0**<br><br>**5,0** | **10,0**<br><br>**5,0** |
| 17. | «Иделкәй» театр коллективларының республика конкурс | Апрель | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» | **8,0** | **8,0** | **8,0** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | фестивалендә катнашу | | МУ | | | |
| 18. | Белем бирү учреждениеләре укучылары арасында халыклар дуслыгы темасына балалар рәсеме конкурс-күргәзмәсе | Уку елы дәвамында | Район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ | **5,0** | **5,0** | **5,0** |
| 19. | Район ансамбльләренең «Каравон» рус фольклоры бәйрәмендә катнашуы | Май Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольское авылы | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| 20. | Район фольклор коллективларының мари мәдәниятенең «Семык» республика бәйрәмендә катнашуы | Июнь | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br>«ТР мариларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасының Кукмара бүлекчәсе | **15,0**<br>**-** | **15,0**<br>**-** | **15,0**<br>**-** |
| 21. | Район фольклор коллективларының «Гырон быдтон» удмурт мәдәнияте республика бәйрәмендә катнашуы | Июнь | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br>Район мәгариф бүлегенең «ТР удмуртларының милли-мәдәни автономиясе» җирле иҗтимагый оешмасы | **20,0**<br>**-** | **20,0**<br>**-** | **20,0**<br>**-** |
| 22. | Татар халык бәйрәме Сабантуй<br><br>Россия төбәкләрендә Сабантуй бәйрәмен | Июнь<br><br>Июнь | Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты, район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» | **150,0** | **150,0** | **150,0** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | оештыруда һәм үткәрүдә катнашу | | МУ<br><br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **250,0** | **250,0** | **250,0** |
| 23. | «Питрау» керәшен мәдәнияте республика бәйрәмендә катнашу | Июль, Мамадыш муниципаль районының Җөри авылы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, «Татарстан Республикасы керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы» Кукмара бүлекчәсе | **20,0** | **20,0** | **20,0** |
| 24. | Татарстан Республикасы көненә һәм Кукмара шәһәре көненә багышланган чаралар | Август | Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты, район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **203,0** | **203,0** | **203,0** |
| 25. | «Крутушка» Халыкара этник фестивалендә катнашу | Август, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Крутушка | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **20,0** | **20,0** | **20,0** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | поселогы | | | | |
| 26. | Бөтенроссия Спас ярминкәсендә катнашу | Август, Алабуга шәһәре | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **20,0** | **20,0** | **20,0** |
| 27. | «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивалендә катнашу | Август-Сентябрь, Казан шәһәре | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| 28. | «Идел Йорт» театр коллективларының фестиваль-конкурсында катнашу | Ноябрь | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **30,0** | **30,0** | **30,0** |
| 29. | «Шома бас» район смотр конкурсын оештыру | Апрель | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| 30. | «Эктон дыр» удмурт биюенең төбәкара смотр-конкурсын оештыру | Апрель | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br>- Район мәгариф бүлегенең «ТР удмуртларының милли-мәдәни автономиясе» җирле иҗтимагый оешмасы | **20,0** | **20,0** | **20,0** |
| 31. | «Уйна, гармун» гармунчылар республика конкурсында катнашу | Ел дәвамында | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| **III бүлек Гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгыту буенча чаралар** | | | | | | |
| 32. | Мәдәниятара мөнәсәбәтләр торышының актуаль мәсьәләләре турында фикер алышуга һәм толерантлык һәм үзара хөрмәт идеалларын алга этәрүгә | Квартал саен | Район Башкарма комитетының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторы | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | юнәлдерелгән семинарлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр һәм башка чаралар оештыру | | | | | |
| 33. | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар җитәкчеләре өчен белгечләр җәлеп итеп, уку курслары оештыру | Елга ике тапкыр | Муниципаль район Башкарма комитеты | - | - | - |
| 34. | «Без бер телдә елмаябыз» оешмасына йөрүче балигъ булмаганнар белән «Нараткай» лагерында җәйге иҗат сменасын оештыру | Июль | «Район мәдәният йорты» МБУ | - | - | - |
| 35. | Республика көненә багышланган күпмилләтле халык иҗаты фестивале | Август | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **16,0** | **16,0** | **16,0** |
| 36. | «Сөмбелә» халык бәйрәме | Октябрь | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ | **16,0** | **16,0** | **16,0** |
| 37. | Халыклар бердәмлеге көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар | Ноябрь | Район Башкарма комитеты, район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе», «Мәдәният идарәсе», «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» | **12,0**<br><br>**1,0** | **12,0**<br><br>**1,0** | **12,0**<br><br>**1,0** |
| 38. | «Жингырты удмурт кырзан» («Яңгыра, удмурт җыры») төбәкара фестивале | Ноябрь | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>Район мәгариф | **20,0** | **20,0** | **20,0** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бүлегенең «ТР удмуртларының милли-мәдәни автономиясе» җирле иҗтимагый оешмасы | | | |
| 39 | «Чеберина – 2019» («Удмурт чибәре») район конкурсы | Ел саен<br>апрель | «ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ<br>Кукмара муниципаль районы «Халыклар дуслыгы йорты» МБУ | **2,7** | **2,7** | **2,7** |
| 40 | Удмурт яшьләре арасында «Устопияш» («Добрый молодец») район конкурсы | Ел саен<br>февраль | «ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ<br>Кукмара муниципаль районы «Халыклар дуслыгы йорты» МБУ | **-** | **-** | **-** |
| 41 | Удмурт яшьләре арасында «Егиткуараос» («Яшь тавышлар») район конкурсы. | Ел саен ноябрь | «ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ<br>Кукмара муниципаль районы «Халыклар дуслыгы йорты» МБУ | **5,2** | **5,2** | **5,2** |
| 42 | «Татар кызы» район бәйгесе | ел саен | «Мәдәният идарәсе» МУ<br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **5,2** | **5,2** | **5,2** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Кукмара муниципаль районы «Халыклар дуслыгы йорты» МБУ | | | |
| **IV бүлек Туган телне саклау һәм куллану, милли мәгарифне үстерү, фәнни тикшеренүләр оештыру** | | | | | | |
| 43. | Шагыйрь, Советлар Союзы Герое М. Җәлилнең туган көненә багышланган чаралар | Февраль | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **3,0**<br><br>**5,1** | **3,0**<br><br>**5,1** | **3,0**<br><br>**5,1** |
| 44. | Бөтендөнья туган тел көненә багышланган республика чаралары | Февраль | Район Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ<br><br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **3,0** | **3,0** | **3,0** |
| 45. | Педагоглар өчен республика семинарларында катнашу | Февраль | Район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ | **1,5** | **1,5** | **1,5** |
| 46. | Район тел олимпиадаларын үткәрү, укучыларның республика (төбәкара) фән олимпиадаларында катнашуы | Февраль-Март | Район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ | **15,0** | **15,0** | **15,0** |
| 47. | Татар әдәбияты классигы Г.Тукайның туган көненә багышланган чаралар. Туган тел көне | Апрель | Район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ<br><br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | спорт идарәсе» МУ | | | |
| 48. | Музейда һәм китапханәләрдә Славян язуы һәм мәдәнияте көненә багышланган чаралар | Май | Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы, район Туган якны өйрәнү музее<br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **3,0** | **3,0** | **3,0** |
| 49. | Бөек рус шагыйре А.С. Пушкинның туган көненә багышланган чаралар. Рус теле көне (аерым план буенча) | Июнь | Район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ<br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **2,0**<br>**0,5** | **2,0**<br>**0,5** | **2,0**<br>**0,5** |
| 50. | Мәдрәсә каршындагы лагерьлар һәм Кукмара шәһәренең якшәмбе мәктәбе | Июнь-Июль | Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты, район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ, мөхтәсибәт, Кукмара благочиниесе | **100,0** | **100,0** | **100,0** |
| **V бүлек Дини оешмалар белән хезмәттәшлек** | | | | | | |
| 51. | Муниципаль район Башлыгы һәм дини конфессияләр, милли берләшмәләр вәкилләре катнашында түгәрәк өстәл утырышы | Ай саен | Район Советы Аппараты, муниципаль район Башкарма комитеты | **-** | **-** | **-** |
| 52. | Мәүлид ән Нәбине бәйрәм итү чаралары | | Район Башкарма комитеты, мөхтәсибәт | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| 53. | Христосның Раштуа бәйрәме буенча чаралар: | 7 гыйнвар | Рус мәдәнияте җәмгыяте | **-** | **-** | **-** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | - Яр буенда Раштуа бәйрәме<br>- Прп. Ксения Римлянина гыйбадәтханәсе каршындагы якшәмбе мәктәбендә тәрбияләнүчеләр әзерләгән Раштуа әкияте | | | | | |
| 54. | Халыкара Раштуа укулары кысаларында чаралар | Аерым план буенча | Район Башкарма комитеты, Кукмара благочиниесе | **5,1** | **5,1** | **5,1** |
| 55. | Кач ману (Крещение Господне) көненә чаралар | Гыйнвар | Район Башкарма комитеты, Кукмара благочиниесе | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| 56. | Белем бирү учреждениеләрендә «Дини мәдәният һәм дөньяви этика нигезләре» уку курсы буенча белем бирү мәктәпләре укучыларын укыту | Ел дәвамында | Район Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ | **-** | **-** | **-** |
| 57. | Православие китабы көнен бәйрәм итү чаралары (күргәзмәләр, конкурслар, түгәрәк өстәлләр) | Февраль | Кукмара благочиниесе, үзәкләштерелгән китапханәләр системасы | **2,5** | **2,5** | **2,5** |
| 58. | Коръән уку бәйгесе (муниципаль этап, республика этабы) | Апрель | Мөхтәсибәт | **30,0** | **30,0** | **30,0** |
| 59. | Православие Пасхасын бәйрәм итү чаралары | | Кукмара районы | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| 60. | «Изге Болгар җыены» Тантаналы чараларында катнашу | Май<br>Болгар шәһәре, Болгар дәүләт тарих- | Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты, мөхтәсибәт | **-** | **-** | **-** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | архитектура музей тыюлыгы | | | | |
| 61. | Бөтенроссия кыңгырау чыңы фестивалендә катнашу | Июль, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск авылы | Район Советы һәм Башкарма комитеты, Кукмара благочиниесе | **4,5** | **4,5** | **4,5** |
| 62. | Мөселман бәйрәме «Ураза гаете»нә багышланган чаралар | | Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты, мөхтәсибәт | **50,0** | **50,0** | **50,0** |
| 63. | Шәһәр мәдрәсәсендә, Республика белем бирү учреждениеләрендә руханилар өчен квалификация күтәрү курслары | Ел дәвамында | Мөхтәсибәт | **40,0** | **40,0** | **40,0** |
| 64. | «Корбан бәйрәме»н бәйрәм итү буенча чаралар | | Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты, мөхтәсибәт | **10,0** | **10,0** | **10,0** |
| 65. | «Корбан ашы» гомумшәһәр мәҗлесе | | Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитеты, мөхтәсибәт | **-** | **-** | **-** |
| **VI бүлек Дәүләт милли сәясәтен мәгълүмати тәэмин итү, нәшрият эшчәнлеге** | | | | | | |
| 66. | «Алтын каләм» – «Золотое перо» республика балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестивалендә катнашу | Казан шәһәре | «Хезмәт Даны – Трудовая Слава» «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы<br><br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **-**<br><br>**1,2** | **-**<br><br>**1,2** | **-**<br><br>**1,2** |
| 67. | «Многоликая Россия» Бөтенроссия журналистлар конкурсында катнашу | Казан шәһәре | «Хезмәт Даны – Трудовая Слава» «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы | **-** | **-** | **-** |
| 68. | «Хезмәт Даны – | Ай саен | «Хезмәт Даны – | **-** | **-** | **-** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Трудовая Слава» район газетасы һәм «Кукмара авазы» радиоэфирында район территориясендә яшәүче халыкларның бердәмлеге темасына багышланган мәкаләләр һәм радиотапшырулар циклы | | Трудовая Слава» «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы | | | |
| 69. | Район газетасы «Хезмәт Даны – Трудовая Слава» битләрендә һәм «Кукмара авазы» радиоэфирында дини-милли экстремизмга каршы юнәлдерелгән мәкаләләр һәм радиотапшырулар циклы | Атна саен | «Хезмэт Даны – Трудовая Слава» «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы | - | - | - |
| 70. | Этноконфессиональ тематика буенча ММЧ (электрон, басма) материалларына мониторинг һәм анализ | Ел дәвамында | Муниципаль район Башкарма комитеты | - | - | - |
| **VII бүлек Этник һәм дини экстремизмны профилактикалау, этникара конфликтларны кисәтү буенча чаралар** | | | | | | |
| 71. | «Экстремизму – ЮК!» республика айлыгы | Сентябрь | Районның террорчылыкка каршы комиссиясе,<br>Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **2,0** | **2,0** | **2,0** |
| 72. | Толерантлык тәрбияләүгә һәм экстремизмны профилактикалауга багышланган | | Район Башкарма комитеты, Террорчылыкка каршы комиссия, | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | белешмәлекләр (памятка) бастыру | | Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ | **0,5** | **0,5** | **0,5** |
| 73. | Район территориясенә килүче чит ил гражданнары турында ведомствоара мәгълүмат алмашуны оештыру | Ел дәвамында | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районындагы бүлегенең миграция мәсьәләләре бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), авыл җирлекләре башлыклары | - | - | - |
| 74. | Мигрантларга түләүсез юридик, консультатив ярдәм күрсәтү һәм оештыру | Ел дәвамында | Район Башкарма комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгының ТР буенча Кукмара районындагы бүлегенең миграция мәсьәләләре бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 75. | Милли берләшмәләр һәм дини оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыручы дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре белән шөгыльләнүче дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү | Ел дәвамында, аерым план буенча | Район Советының кадрлар һәм муниципаль хезмәт бүлеге | - | - | - |
| 76. | Халыкара толерантлык көненә багышланган чаралар | Ноябрь | Белем бирү уку йортлары | - | - | - |
| 77. | Уку йортлары укучылары арасында | Ел дәвамында | Россия Эчке эшләр министрлыгының | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | милләтара һәм конфессияара нигездә экстремистлык күренешләрен булдырмауга юнәлдерелгән оператив-профилактик чаралар комплексы үткәрү | | Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча) | | | |
| 78. | Терроризмга һәм экстремизмга каршы тору буенча профилактик эш алып баручы затлар өчен квалификация күтәрү курслары (дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, җәмәгать оешмалары вәкилләре, хокук саклау һәм суд органнары хезмәткәрләре) | Ел дәвамында | Район Советының кадрлар һәм муниципаль хезмәт бүлеге | - | - | - |
| | **БАРЛЫГЫ:** | | | **1508,0** | **1508,0** | **1508,0** |